**Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының
Аппак авыл җирлеге Советы
КАРАРЫ**

2015 елның 1 апреле 14№

**Әлки муниципаль районы Аппак авыл җирлеге Советының 2014 елның 24 июнендәге "Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Аппак авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турындагы Нигезләмә хакында" 13 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында**

2014 елның 22 декабрендәге «Коррупциягә каршы көрәш мәсьәләләре буенча Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 431-ФЗ номерлы Федераль закон кабул ителүгә бәйле рәвештә Әлки муниципаль районы Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Әлки муниципаль районы Аппак авыл җирлеге Советының 2014 елның 24 июнендәге "Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Аппак авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турындагы Нигезләмә хакында" 13 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 7 статьяның 1 өлешендәге 1 пунктын үз көчен югалткан дип танырга;

1.2. 7 статьяның 1 өлешендәге 3 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «3) әгәр федераль законнарда башкасы каралмаган булса, яисә федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә муниципаль хокукый актта билгеләнгән тәртиптә, аңа әлеге оешма белән идарә итүдә катнашырга йөкләнмәгән булса, эшмәкәрлек эшчәнлеге белән шәхсән яки ышанычлы затлар аша шөгыльләнергә, шулай ук хуҗалык итүче субъект (торак, торак-төзелеш, гараж кооперативларыннан, бакчачылык, яшелчәчелек, дача кулланучылар кооперативларыннан, күчемсез милек милекчеләр ширкәтеннән һәм һөнәр берлегеннән тыш) белән идарә итәргә».

2. Әлеге карарны Әлки муниципаль районы Аппак авыл җирлегенең мәгълүмат стендында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Әлки муниципаль районы Аппак
авыл җирлеге башлыгы урынбасары: Л.И.Казакова